**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**МӘЛЛӘ-ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ**

**IV ЧАКЫРЫЛЫШ LXIII УТЫРЫШЫ**

**КАРАР № 88**

Мәллә-Тамак авылы «24» март 2025 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районың Мәллә-Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 31 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мәллә-Тамак авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын да кертеп, аның график сурәте белән бергә (2 нче кушымта), әлеге карар кабул ителгәннән соң 5 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (muslumovo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлегенең Мәллә-Тамак, Нарат-Асты авыллары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча халыкка җиткерергә:

   Мәллә-Тамак ав., Кооператив ур., 32А йорт (мәдәният йорты бинасы);

   Нарат-Асты ав., Урман ур., 34 йорт (авыл клубы бинасы).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Мәллә-Тамак авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Насифуллина

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Мәллә-Тамак авыл җирлегенең
24 март 2025 ел 88 номерлы
карарына 1 нче кушымта

# СХЕМА

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мәллә-Тамак авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органына депутатлар сайлау округлары .

| № п/п | сайлау округының исеме, № | Сайлау округына керүче торак пунктлар | Сайлау округына керүче урамнар исеме | сайлау округына керүче йортларның номерлары | сайлаучылар саны |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Мәллә-Тамак № 1 | Мәллә-Тамак авылы | Яр буе урамы | тулысынча | 71 |
| | | | Тукай урамы | №№ 1 – 29<br>№№ 2 – 28 | |
| 2 | Мәллә-Тамак № 2 | Мәллә-Тамак авылы | Тукай урамы | №№ 31 – 69<br>№№ 30 – 90 | 67 |
| 3 | Мәллә-Тамак № 3 | Мәллә-Тамак авылы | Кооператив урамы | №№ 1 – 53<br>№№ 2 – 56 | 68 |
| 4 | Мәллә-Тамак № 4 | Мәллә-Тамак авылы | Колхоз урамы | тулысынча | 62 |
| | | | Кооператив урамы | №№ 55 – 73<br>№№ 58 – 70 | |
| | | | Яшьләр урамы | №№ 1 – 7<br>№№ 2 – 6 | |
| 5 | Мәллә-Тамак № 5 | Мәллә-Тамак авылы | Кооператив урамы | №№ 75 – 113<br>№№ 72 – 110 | 68 |
| 6 | Мәллә-Тамак № 6 | Мәллә-Тамак авылы | Яшьләр урамы | №№ 8 – 10 | 63 |
| | | Нарат-Асты авылы | Урман урамы | №№ 1 – 23<br>№№ 2 – 24 | |
| 7 | Нарат-Асты № 7 | Нарат-Асты авылы | Урман урамы | №№ 25 – 81<br>№№ 26 – 78 | 67 |

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль
районы Мәллә-Тамак авыл
җирлегенең 24 март 2025
ел 88 номерлы карарына
2нче кушымта

## Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлегенең бермандатлы сайлау округы схемасының график сүрәте

